Чыганак: Мирас.-2008.- № 12.- Б. 50-65

**ПЕДАГОГИК МИРАС**



# НӘБИ ДӘҮЛИ ШИГЪРИЯТЕ

Нәби Дәүли әдәбиятка шагыйрь буларак килеп керә.

«Җыр юлы авыр, җыр юлы ерак»,— ди Нәби Дәүли үзенең «Шагыйрь анасына» шигырендә. Бу, чыннан да шулай, аның үзенә карата бигрәк тә... Балалар йортында тәрбияләнеп үскән, Донбасс шахталарында эшләгән һәм беренче бишьеллыклар романтикасы белән рухланып әдәбиятка килгән Нәби Дәүли үзе дә, аның поэзиясе дә Бөек Ватан сугышы елларында яшәү белән үлем арасында торып көрәшә. Бу рәхимсез бәрелештә кеше һәм җыр җиңеп чыгалар. Аның әсәрләрен укыгач, без чын тормыш белән, шагыйрьнең намусы һәм вөҗданы, теләк һәм омтылышлары белән очрашабыз. Һәрбер әдәби әсәрнең, бигрәк тә поэтик әсәрнең көче укучы күңеленә һәм акылына тәэсир итә алырлык фикерләрнең һәм хисләрнең тирәнлеге, аларны гомумиләштерүнең зурлыгы белән үлчәнә. Нәби Дәүли кешеләр язмышы, аларның тормыштагы урыны һәм эшләре турында җырлый.

А.В.Луначарский «Үсешне аңламаган кеше хакыйкатьне бервакытта да күрми; чөнки хакыйкать ул үз-үзенә охшамаган, ул бер урында утырмый, хакыйкать оча, хакыйкать ул үсеш, хакыйкать — ул конфликт, хакыйкать — ул көрәш, хакыйкать ул иртәгәге көн...»,— дип язган иде. Нәби Дәүли тормыш хакыйкатен нәкъ менә шулай аңлый, туктаусыз оча торган хакыйкать артыннан калышмаска һәм аны үзенең иҗатында чагылдырырга омтыла. Шагыйрьнең шигърият дөньясына басуы романтик, үзенчәлекле утызынчы елларга авылда һәм шәһәрдә җәелеп киткән социалистик төзелешләр һәм яңарышлар темасына борылган чакка туры килә. Әдәбият белән тормыш арасындагы бәйләнешнең яңа формалары (предприятиеләргә, бөек төзелешләргә, колхозларга иҗат командировкалары, турыдан-туры җитештерүдә эшләү, укучылар конференцияләре уздыру) поэзиянең географик һәм тематик чикләрен киңәйтә, иҗат принципларын баета, яңа жанрларны хәрәкәткә китерә.

Нәби Дәүли иң тәүге поэтик адымын заманында редакторы Муса Җәлил булган «Октябрь баласы» журналы битләрендә 1929 елда ясый. Утызынчы еллар азагында инде без аны, штурвалны ышанычлы куллар белән тоткан килеш, зур корабта күрәбез. Поэзия дөньясына керү дигән чиксез җаваплы бу хәлгә аның соңгы шигырьләренең берсендә



әйтелгән бик табигый һәм зирәк искәрмәсе бар:

«Поэзиягә мин дә сокландым,  
Шул бакчага кердем бер иртән.  
Керүен мин кердем, дусларым,  
Чыгар өчен капка юк икән.»

*«Бакча»*

«Керүен дә кердем, дусларым, чыгар өчен капка юк икән». Без моны: әдип таланты халыкныкы ул, талантны, үз-үзеңне аямыйча эшләп, гомер-гомергә, халыкка хезмәт иттерергә кирәк! — дигән мәгънәдә аңлыйбыз. Нәби Дәүли шул вазифаны үтәүгә бар дәрте белән, бөтен йөрәген биреп керешә.

Шагыйрьнең «Күптән язылган» (1936 ел) исемле шигырендә бик уңышлы яңгыраган символик мәгънә һич тә очраклы түгел. Анда Казан каласының «булачак бер иртәсе» күз алдына китерелә.

Менә шуннан китәр кораблар  
Ерак илгә Казан йортыннан.  
Диңгездәге маяк яктылыгы  
Күренеп торыр минем йортымнан!

1937-1941 еллар эчендә Н.Дәүлинең дүрт җыентыктан торган шигырьләр китабы дөнья күрә. Аның беренче җыентыгы 1937 елда «Бәхет», 1939 елда «Ал чәчәк», 1940 елда «Уйлар» һәм 1941 елда «Кырык шигырь» дигән исем белән чыга. 1937, 1939 елларда басылган «Бәхет» һәм «Ал чәчәк» җыентыкларының характерлы ягы — бәхеткә омтылу һәм чәчәккә, кояшка мәхәббәт. Чәчәксез һәм кояшсыз булган шигырьләр бик аз монда. (Бәлки бу хәл шул чор әдәбиятының оптимистик, шатлыклы булуы белән кояшка һәм чәчәккә ода җырлауны да һичшиксез таләп итүеннәндер). Н.Дәүли «Ал чәчәк» шигырендә яшьлек, кояш, чәчәк матурлыгын җылы, татлы тойгылар һәм яшәүгә бетмәс мәхәббәт күрсәтү лирикасы аша җырларга омтыла.

Кояш карый зәңгәр биеклектән,  
Бәхетемне минем көнләшеп,  
Мин бакчада гөлләр арасында,  
Чәчәк белән йөрим сөйләшеп,  
Күр, ал чәчәк, минем яшьлегемне,  
Көнләшмичә карый аламсың?  
Канат үсте минем йөрәгемә,  
Бәхтен тапты ялчы баласы.

*«Ал чәчәк»*

Тормыш матурлыгын табигать бөеклегенә дә бәйли белеп, яшәү ләззәтенең монументальлеген укучыга җиткерә белү шагыйрьнең бурычы булуын Нәби Дәүли ул чакта ук сизгән күрәсең. Тагын берничә шигырьгә тукталып китик:

Тулып-тамып ага Мәскәү елга,  
Дулкыннары кага ярларга,  
Мәскәү — елга сөйләр кайгы җырын  
Безнең арттан килгән елларга.

*«Ильич» шигыре*

Шагыйрь Ильич үлемен ил, халык кайгысы белән яхшы ук кына уңышлы рәвештә конкрет образларга бәйләргә тырышкан.

Чикне атлап чыксаң теге якка,  
Сине илең мәңге кичермәс,

Бакчасыннан сиңа алма бирмәс,
Елгасыннан суын эчермәс.
(«Халык улы»)

Шагыйрь монда ватанга хыянәт итүнең җәзасы рәхимсез булуын яңача итеп әйтүгә таба бара.

Яки «Безнең авыл» шигырендәге:

Юк, кешене алай картайтмыйлар,
Ирек булса аңа яшәргә!
Йөрәкләре тулы — шатлык белән,
Келәтләре тулы — мал белән,

кебек җиңел поэтик афоризмсыман юллар урынлы, художестволы казаныш булып тора.

Нәби Дәүлинең бу чор иҗатында Һади Такташ шигъриятендәге Ташкент чоры (1921-1922) йогынтысы сизелә. Чөнки Һ.Такташ үзенең беренче дәвер әдәби эшчәнлегендә күренекле урын тоткан романтик әсәрләрен — әчтәлеге белән нигездә мифологик, символик образлар аша кеше шәхесенең рухи хөрлеген данлаган, аны буып торган явыз көчләргә, дини хорафатларга, социаль гаделсезлеккә каршы ярсулы көрәш, гыйсъянчылык идеясен алга сөргән бер төркем шигырьләрен («Онытылган ант», «Күләгәләр», «Нәләт», «Таң кызы», «Урман кызы» һәм атаклы «Җир уллары» трагедиясен) иҗат итә.

Ә менә 1940 һәм 1941 нче елны чыккан шигырь җыентыкларында инде шагыйрьнең поэтик ярлылыктан киңрәк юлга чыгарга тырышуы күренә.

Н.Дәүлинең «Уйлар» 1940 нче елны дөнья күргән шигырь җыентыгын укып чыкканнан соң Г.Кутуй шагыйрьгә ачык хат яза:

*«Дәүли туган!»*

*Сез үзегез турында күп сөйләшә торган шагыйрь. Бу яхшы хәл, әлбәттә. Чөнки сез безнең яшь шагыйрьләребез арасында өметле күренгәннәрнең берсе. Сезнең иҗат укучыларны дулкынландыра, аларда яхшы тойгылар уята, матур фикерләр тудыра. Сездә матурлыкны күрү һәм шуны матур итеп бирә белү көче бар. Мин сезнең әле күптән түгел генә басылып чыккан «Уйлар» исемле җыентыгыгызны укыдым. Анда кабат-кабат укыла торган һәм укыган саен кешегә ләззәт бирә торган «Йолдызлар», «Дуслык турында», «Кремль курантлары», «Яшьлек килә» һәм «Партизан кылычы» шикелле әйбәт шигырьләр бар.*

*Бу җыентыкны уку миндә сезне сәләтле шагыйрь итеп табу фикерен тагы да көчәйтте. Ә бу хис беренче тапкыр сезнең гаять җанлы язылган «Ильич» шигырегезне укыганнан соң туган иде.*

*Сезнең шигырьләр миңа кадерле укып утыру сәгатьләрен бирделәр һәм сезнең шигырьләрегез үк шул кадерле сәгатьләргә ямьсезлек тә керттеләр. Менә шуны аңлатыр өчен мин сезгә «ачык хат» язарга утырдым.*

*«Теләк» исемле әсәрегездә сез «Җырда — халык үе, шагыйрь тавышында — ил теләге яши» дисез. Бик дөрес һәм бик кыйммәтле сүзләр, һәм сез моны күп кенә шигырьләрегездә расладыгыз да инде. Ләкин... Сизәм, сез каш җыерасыз. Зарар юк. Мин дә сезне укудан туган кадерле сәгатьләргә үзегез үк ямьсезлек керткәндә: «Ни өчен болай язабыз? Нишләде Дәүли?» — дип ачынып сораулар биреп утырдым.*

*«Дүрт чәчәк» шигырендә Сез зәңгәр чәчәккә мактау җырлыйсыз. Ник?*



*Чөнки минем сөйгәнемнең*
*Күзләре шундый зәңгәр,—*
*дип дәлил китерәсез. Ә «Волга ярында» исемле әсәрегездә сөйгән кызыгызга карата әче сүзләр әйтәсез:*
*Башка булсын кияү синең туйда,—*
*Мин башканы сөям яңага.*

*Мин Сезне җитди шагыйрь дип беләсем килә һәм җитди шагыйрьнең иҗатында идея берлеге, идея бөтенлеге сакланырга тиеш дип аңлыйм. Ә сез, вакыт-вакыт менә шул бөтенлекне җимерәсез, нигездә үсүгә таба юл тоткан әдәби хезмәтегезне үзегез бөек дип тапкан халык уеннан, ил теләгеннән читкә өстерисез.*

*...Минемчә, сез хис белән, йөрәк белән яшәргә яратасыз, акылга буйсынудан баш тартасыз. Һади Такташ та хис белән яшәде. Ләкин ул кирәк чагында, иҗат минутларында, «күңел азганда»:*
*Ирке чикләнмәгән йөрәгемә*
*Башлык итеп куйдым акылны,—*
*дип әйтергә мәҗбүр булды. Такташтан үрнәк алыгыз, ялгыш ноталарга бирелмәгез, тавышыгызны бозылудан саклагыз диясе килә. Сез бераз гына философ та. Бу да яхшы хәл, әлбәттә. Ләкин сез, Дәүли туган, кечкенә генә бер җыентыкка да берсе-берсенә капма-каршы булган әсәрләр язуыгызны сизми каласыз. Мәсәлән, «Дуслык турында» шигырендә сез йөрәкне ачарга, дуслык өчен йөрәкне дә кызганмаска кирәк дип дәгъва кыласыз. Ә «Бер кызның альбомына» шигырендә үз йөрәгегезне бирә алмау турында әйтәсез, өченче бер шигырендә исә «йозакка ачкыч табыла, ә йөрәккә — ачкыч юк» дип бу турыда фәлсәфә сатуны шаяртуга әйләндерәсез...*

*Өзек-өзек җөмләләрдән яхшы теләкләремне аңларсыз дип уйлыйм. Уңышлы иҗатыгызны көтеп, сәлам белән:*

*Гадел Кутуй. 1941.*

(Кутуй Г. Публицистика.— Казан, 1957.— Б. 192–196.)

Бу җыентыкларның уңышлы ягы — әнә шул ярлылыкны, шаблонлыкны, стандартлыкны, хиссезлекне бетерергә теләп, уйлар, табигый хисләр бирергә омтылуда. «Мин — синең улың», «Тарихтан өзек», «Бишек җыры», «Доктор белән сөйләшү», «Сарай каршында уйлану», «Тау буенда ялгыз һәйкәл тора», «Елама, бала» кебекләрне уй һәм тойгы алырлык үзәккә тупланып тудырылган әсәрләр итеп карарга мөмкин. «Тарихтан өзек» әсәрендә шагыйрь туган илен туздырырга теләгән сугыш чукмарларына карата шигырьнең аерым өлешендә бик үткен һәм яңа, сатирик картина бирә. «Доктор белән сөйләшү»дә яшәргә һәм җырларга ашкынуны поэтик сюжет рамкасына кертеп бирүе дә үзенчәлекле. Лермонтовның үлмәс даһилыгына багышланган «Тау буенда ялгыз һәйкәл тора» шигырендә данлы җырчыга булган җылы дуслык, мәхәббәт хисләре һәм Лермонтовны үтерүче җәмгыятькә карата шулар эчендә табигый аралашкан нәфрәт ялкыны бик ягымлы һәм образлы булып сизелеп тора. Бу җыентыкта шагыйрь табигатькә мөнәсәбәтен дә конкретрак күрсәтергә омтыла. Ягъни, табигать белән кешенең эчке дөньясының билгеле бер бәйләнешен, мөнәсәбәтен табарга тели. «Ташулар җырлый», «Умырзая көлә», «Кунаклар килә» кебек шигырьләрдә шагыйрь табигатьнең кешегә, үзенә һәм безгә бирә торган җылылыгын һәм безнең шатлыклы, канәгатьләнүне сиземләвебезне сурәтләргә омтылыш ясый.

«Ал чәчәк» җыентыгында ук шагыйрь татар поэзиясе традиция-

сендәге ритмик бертөрлелектән котылырга тели. Шуннан соңгы шигырьләрендә берничә ритмик алым куллана; иҗек саны ягыннан да, басым, интонация ягыннан да аерылып торучан үрнәкләр бирә. Рифмалар өстендә эшләү, ягъни аркылы рифмаларны күп куллану да Нәби Дәүлинең шигърияттәге үсешен күрсәтә.

Шушы чорда иҗат итүче башка шагыйрьләрнең дә җитешсезлеге булган поэтик объектларның, сурәтләнә торган темаларның аз булуы; булганнарының да бик өстән генә чагылдырылуы Н.Дәүлигә дә хас. Тормыштагы оригиналь сюжет бирүче вакыйгалар һәм фактлар аз. Художестволы кискен һәм акылга бай шигъри объектлар уйлап чыгарылмый; матбугатта сөйләнә торган һәм гадәти көнкүрештәге эшләнеп беткән стандарт акыл рамкаларыннан читкә чыгып, киң фантазиягә, уйлап табуларга юл бирелмәгән. Г.Халит шул вакытларда: «Хәзерне ашап яту, тапканны табу һәм яхшыны начарайту, тәмлене тәмсезләтү белән җәмгыять каршында мактанып булмый, билгеле. Без үзебезнең ватаныбызны һәм партиябезне яратабыз, дуслык, мәхәббәт һәм батырлыкны үз рухыбызның бөек сыйфатлары итеп таныйбыз. Ләкин поэзиядә аның чагылышы бик абстракт һәм бик өстән-өстән генә әле. Көндәлек матбугатта сөйләнә торган лозунглы коры материалны рифмага салып кына поэзия тудырып булмый. Ул — чи материал гына була ала, ә шагыйрь аны җанландырырга, рухландырырга һәм тулы канлы итеп, әдәби югарылыкка күтәреп бирергә тиеш. Маяковский заем турында яза, ләкин тере рухлы сәнгать ясый ул аны. Н.Тихонов бик гади әйбер — кадак төшенчәсе белән бәйләп, баллада яза; аны укыгач, гаҗәпсенеп: шагыйрь каләме кешеләр белән мөнәсәбәттә кадаклы да, рухлы да, ләззәтләндерерлек һәм социаль аң бирә алырлык поэзия итә ала икән!— дисең», — дип язган иде.

Н.Дәүлинең шушы чор шигъриятенең уңышлы ягы — конкрет темаларга бәйләнгән уй һәм кичерешләрнең тәмамлану чиген, сюжеттагы индивидуаль таяну ноктасын табарга тырышуы һәм шигырьләре сюжетында еш кына әкият элементларын кертүе. Дәүлинең бу алымы күбесенчә табигатьтәге предметларны сынландыручы метафораларга күчерү белән бәйле: йолдызларны, тауларны һәм кешеләрне, кояшны сөйләштерү һ.б.

Шагыйрь хис-кичереш дөньясын сурәтләгәндә даими эпитет, чагыштыру, гипербола һәм бүлгән троплар байлыгын мул куллану белән эмоцианальлеккә, образлылыкка ирешә. Ачык куе төсләр, антитеза чаралары күңел дөньясының катлаулы халәтен ачарга ярдәм итә.

Бу ике җыентыкта поэтик сурәтләү чаралары — «алтын яфраклар», «ефәк шәлле таллар», «якты кызыл байрак», «алсу байрак», «ефәк кигән басулар», «балкып чыкты тормыш», «балкыды кояш», «балкый байрак», «тын кыр», «тын бакча», «тын елга», «тын урман», «тын гына ята», «тын гына сулый», «тынган булса саф йөрәк», «якты кояш», «якты йолдыз», «якты ай», «якты мәктәп», «шатлык белән йөзе яктыра», «көмеш ай», «ал букет», «алсу букет», «хуш исле букет», «букет бирде», «ал чәчәк», «матур чәчәк», «кызыл гөлләр», «кояшлы ил», «кояшлы җир», «уйлар кабыналар», «хисләр кабыналар», «мәхәббәт кабына», «йолдыз кабына», «капка ачты барыр юлына», «ачкыч бирәм бәхет капкасына» һ.б. шагыйрьнең иң яраткан һәм өзлексез ялтырап, уйлатып торган эпитетлары, метофоралары, персонификацияләре һ.б.

Н.Дәүлинең тормышы утлы сиратларны еш кичәргә, кырыс сынаулларда сынатмаска-сыкранмаска өйрәткән. Дәһшәтле һәм фаҗигале сугыш елларының кайтавазы гына да бәгырьләрдән кан саудырып, җаннарны тетрәндерерлек. Ә аның өлешенә тагын да хәтәррәк борылышлар язган әле... Изге туфрагыбызга мәкерле дошман аяк басканның икенче көнендә үк яу кырына киткән Нәби Дәүли авыр бәрелешләренең берсендә йөзләгән иптәшләре белән чолганышта кала һәм тоткынлыкка төшә. Бу инде икеләтә авыр: язмышының бөтенләй билгесез сукмакларга кереп китүе дә, илдәгеләр өчен «хәбәрсез» югалуы белән дә. Ләкин шагыйрь — гади солдат, гади әсир түгел, ул яшенне үзенә тарткан имән кебек тормышның драматик катлаулыгын бөтен тулылыгы белән үз йөрәге аша үткәрү мөмкинлеге ала. Шагыйрь күңеле башкалар бер кичергәнне мең кичерә, кайта-кайта телгәләнә. Хис-кичерешләр чынлыгы, мең көзге аша үткәреп бер ноктага туплангандай, аерым шәхеснең генә түгел, бөтен бер буынның фаҗигасен күз алдына бастыра. Менә шуның өчен дә Н.Дәүлинең сугыштан соңгы поэзиясе тагын да яңа төсләргә, яңа интонацияләргә баеган.

Шагыйрьнең күпчелек шигъри әсәрләре («Иртәнге җыр» җыентыгы, 1955 ел; «Юлда», 1957; «Мин җирдә калам», 1980 һ.б.) ул кешеләр язмышы, аларның тормыштагы урыны һәм эшләре турында. Н.Дәүлинең сугыштан соңгы чордагы иҗатының асылы нидә, ул нәрсә турында күбрәк язган соң? — дигәндә: Нәби Дәүли иҗаты — Ватан һәм аңа лаеклы булу турында,— дип әйтер идек.

Бәхетлеме кеше дөньяда?
Ят илләрдә рәхәт торса да,
Болытларга кадәр җиткереп
Асыл таштан сарай корса да,
Туган йортның кабат күрмәсә,
Туган җиргә ятып үлмәсә,
Яз көнендә чәчәк куярга
Каберенә дуслар килмәсә,
Бәхетлеме кеше дөньяда?

*«Бәхет турында»*

ди ул бу шигырендә.

Дөньяда иң зур бәхет — үз илеңдә, туган туфрагыңда ятып үлү икән. Бу юлларда шагыйрьнең туган җирне сөюе, аңа чиксез мәхәббәте иң югары ноктасына күтәрелгән, аның Ватан турындагы уй-фикерләре бер фокуска җыеп бирелгән. «Шагыйрьнең бу сүзләрендә зур хаклык бар. Ә Нәби Дәүлинең үзе өчен — бигрәк тә...» — ди Ф.Миңнуллин («Балта явызлар кулында...» Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.— Казан: Татар.кит.нәшр., 1954.-Б. 157-158).

«Шагыйрь — үз заманының авазы»,— дигән иде шагыйрь Гали Хуҗиев Нәби Дәүли шигърияте турында язган мәкаләсендә. Чөнки бөтен иҗатында халык тормышы белән, аның өметләре белән, шатлык һәм кайгылары белән, бөтен кешелек дөньясының язмышына кагыла торган зур мәсьәләләр белән дулкынланып һәм борчылып яши. Мәсәлән, «1945 ел шигыре», «Уйна, кызым», «Мин судка барам», «Бонн генералларына хат», «Сез, чәчәкләр, нәрсә әйтерсез?», «Күрәсезме? Ишетәсезме?» әсәрләрендә автор тынычлык дошманнарына халыкның тирән нәфрәтен белдерә. Кайчандыр үзе тоткын булып үлем көткән шагыйрь, Муса Җәлилне үтергән һәм Фучикны дарга күтәргән палачларны гаепләп, үзен чал чәчләре белән суд алдына дәлил итеп куя.

Күрсәтмәгез миңа кулыгызны,
Кан таплары сезнең кулларда.
Биш бармаклы елан кебек алар,
Сузылганнар кеше буарга.

Манолиска балта күтәрдегез,
Балта очы тиде миңа да.
Мин дә сөям чөнки азатлыкны,
Мин дә кеше шушы дөньяда.

Шагыйрьнең 1980 елда дөнья күргән, иҗатының бер йомгагы рәвешендә, иң яхшы шигъри әсәрләре тупланган «Мин җирдә калам» исемле китабы әле бүгенге көндә дә укучылар тарафынан яратып укыла. Монда Н.Дәүлинең ике поэмасы, өч балладасы, ике йөзгә якын шигырь һәм парчалары туплап бирелгән. Әсәрләр шагыйрьнең поэтик үзенчәлеген, аның иҗади һәм иҗтимагый позициясен тулы итеп күзалларга, кайбер гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирәләр.

Китапның бирелешеннән үк күренгәнчә, аның төп лейтмотивын хезмәт, табигать, кеше һәм аның тормыштагы урыны, яшәү мәгънәсе, гражданлык бурычлары, дуслык, иптәшлек, туганлык, яшьлек һәм мәхәббәт, гаилә һәм аның ныклыгы, киләчәк буын, җир һәм дөнья язмышы турында уйланулар билгели.

Шагыйрь китабын иҗади кредосын билгеләүче шигъри сүз белән башлый. Анда автор үзенең туган җире белән мәңгегә бәйле булуын, аның язмышы, бүгенгесе һәм киләчәге өчен җаваплылык тоюын үтемле итеп күрсәтә, ачык итеп сурәтли. Бу фикер шагыйрьнең «Юл башы», «Мин җирдә калам» әсәрләрендә тагын да калку итеп үстерелә. Аларда җирсез-илсез, дус-тугансыз, сөю-мәхәббәтсез, янусыз, максатсыз, гүзәллек һәм бәхеттән мәхрүм булып, гаиләсез, ялгыз гына яшәү мөмкин түгеллеге исбатлана. Шагыйрь бүгенге чынбарлыкны ачык итеп күрә, тормыш хакыйкатен тирән итеп аңлый һәм аны шигырьләрендә дөрес итеп чагылдырырга омтыла.

Нәби Дәүли күп кенә шигырьләрендә акыл көченә ия булган Җир улы, табигать баласы булып сөйли:

Мин ант итәм Җирнең улы булып,
Хезмәтчесе булып калырга.
Кирәк чакта өскә шинель киеп
Кулларыма кылыч алырга.

Шагыйрь галәм корабларына утырып җиһанны гизеп кайткан, җиде кат җир астына төшеп девон фонтаннары аттырган, салкын ташка җан өргән, басуларда мул уңыш үстергән фидакарьләргә мәдхия җырлый, кеше акылын зурлый. Шуның белән бергә шагыйрь «Син җир баласы», «Үстердеңме чәчәк син үзең», «Табигатьнең зарын ишетсәң», «Аккош күле», «Кем ул явыз», «Каен ярасы» исемле шигырьләрендә табигать белән саксыз эш итүчеләрне, аның гармониясенә зыян китерүчеләрне бөтен җаны-тәне белән тәнкыйтьли итә.

Чәчәкләр җирдән күп өздең,
Үстердеңме чәчәк син үзең?! —

дип сорый ул замандашыннан.

«Мин җирдә калам» шигырендә Н.Дәүли «Мине» — Айга очса, ракетага утыртып кына илтеп куячаклар,— ди. Ай кешесе булып яши калса, мең ел гомере булачак! Җирдәге барлык чәчәкләрне дә аңа истәлеккә бүләк итәчәкләр. Айда яшәү мең ел гомерең булу — кызыктыргыч бит! Нишләргә?



«Мин» Айга менсә, дуслар, туган җирләр кала, мең ел гомерен интегеп, кайгырып, япа-ялгыз, тын шалашта чыра яндырып үткәрергә тиеш. Шагыйрь әнә шулай чагыштырып, каршы куеп, айдагы тормышның әйбәт һәм начар якларын күрсәтә.

«Мин» проблеманы үзе хәл итә: ул җирдә калачак, чөнки аның йөргән сукмаклары монда; дусларсыз мең ел түгел, бер көн дә яши алмый; йөрәк янганда, Идел суларын эчми торып булмый. Җыр ишетмичә һич тә түзәрлек түгел. Таң атканда, тәрәзәдән кояш нурларын да күрәсе килә. Җир җылысын сизмәсә, каны суыныр. Сөйгәне дә монда бит! Аның белән табындагы икмәкне дә бүлешеп була.

Әйе, Җирдә калу күпкә әйбәтрәк икән. Айда юллар киң булса да, җирдәге тар сукмаклар күңелгә якын.

Шагыйрь «мин»нең ни өчен җирдә калуын тагын да тирәнрәк аңлата: Җир — ул туган туфрак, туган як, туган ил, туган тел!

Әлеге лирик әсәрнең төп темасы — туган якны ярату. Ә идеясе — туган йортны, туган якны, туган илне, туган телне Нәби Дәүлинең «мин»е кебек яратырга кирәк.

Шигырьдә «мең ел» сүзтезмәсе өч тапкыр кабатлана:

1. Кеше өчен мең ел гомер — бик күп вакыт. Шуның кадәр яшәп карыйсы килә.

2. Ләкин айда мең ел яшәү — мең ел хәсрәт чигү ул. Бу — адәм түзә алмаслык хәл.

3. Бер көн артык миңа мең елдан,
Айда түгел, туган илемдә! — шигырьнең мәгънәсе.

Шигырьнең исеменә игътибар итик. Шагыйрь әсәрендә төп проблема итеп, туган җирне ташлап китү-китмәү мәсьәләсен куя. Мәсьәләне алдан ук хәл иткәнен күрәбез: «Мин» — лирик герой җирдә кала. «Мин Җирдә калам» — шигырьнең исеме. Җыентыкның исеме дә шулай.

Шагыйрь чагыштыра-чагыштыра, каршы куя-куя, кабатлый-кабатлый, туган туфракның, туган телнең бик изге, бик газиз икәнен исбатлый.

«Дуслык турында» шигырендә Н.Дәүли дуслык хисенең көчле хис булуы турында яза. Моның өчен эчке халәтнең кешеләр тормышында уйнаган ролен күрсәтә.

Сарык ите белән дустыңны сыйлау — бик әйбәт. Ләкин лирик герой моңа риза түгел: табынга дустының йөрәген куюын сорый. Ягъни, ихласлылык, керсез күңел белән аралашу кирәк. Баллы ширбәт агуга әйләнмәсен дисәң, саф күңелле бул. Дуслыкны саклау өчен сүзләр, антлар бирүнең кирәге юк. Ә кайгы килгәндә, бер-береңә терәк булу кирәк. Шул ук вакытта лирик герой дустының горур, кайгы-хәсрәтләргә бирешмәвен, аларны кеше саен өләшеп йөрмәвен, шатлыкларны уртаклаша белүен тели.

Менә шушы матур фикерләрне укучыларына җиткерү өчен, шагыйрь чагыштырулардан файдаланган: Сарык ашы (башы) — йөрәк ашы, Тәмле ширбәт — агу, Җиз — алтын һ.б. Каршылыкларны да күрәбез: Ашамыйм — мин тук (табынга йөрәгеңне куйсаң), Тәмле ширбәт — агу, Мин авам — син терәк бул, Кайгы — шатлык, Тыштан иптәш — эчтән мәкер саклау һ.б.

Бер тамчы су ике кешенең сусавын, әлбәттә, баса алмый. Шагыйрь дуслыкның көчен исбатлау өчен әнә шулай кечерәйтеп, арттырып күрсәтә: саф күңелле булсаң, шул бер тамчы су юлда безне туендыра

ала! Н.Дәүли дуслыкның кадере, сафлыгы, ихласлылыгы турында сөйли.

«Сорау» шигыре бары тик бер генә строфадан тора. Шагыйрь укучысына сорау биреп, бүгенге тормышта иң кирәкле проблеманы — тирә-юнеңдәге кешеләргә яхшы, матур сүзләр әйтергә кирәклеген күтәрә. Яхшы сүзнең бәясен, кыйммәтен аңлату өчен каршы кую алымы кулланылган: Яхшы сүз — начар сүз, Җаның теле — күңелең күрсенә (теләми).

Яхшы сүзне һәрберебез бик тә ишетергә тели. Тик үзең ишеткәнче, башта син аны үзең ишеттер, ягъни үзең әйт.

Шагыйрьнең соравы да шул: «Яхшы сүзне әйтәсеңме башка кешегә?» Нәби Дәүли «Мин җиргә калам» җыентыгында үзенең юмор-сатира жанрында да уңышлы гына эшләвен күрсәтә. Ул үзенең «КаМАЗ» машинасы кирәк миңа», «Мыштым», «Будильник сатып алдым», «Бер хәбәрсез югалдың», «Юл читендә», «Урындык һәм урын турында», «Әтәч турында тагын бер мәсәл» исемле әсәрләрендә җиңел юл белән көн күрергә теләүче әрәмтамакларны, хезмәт кешесенең ихтыяҗларына гамьсез генә караган бюрократларны, үз эшендә брак ясаучыларны, дуслык, иптәшлек мөнәсәбәтен оныткан, иптәшенә ышанычын югалткан, үз кабыгына бикләнеп яшәүче бәндәләрне утлы табада биетә, зәһәр ялкында көйдерә. «Күзәтүләр — сүз әйтүләр бәйләмә»ндәге хикмәтле сүзләр, парчалар да игътибарга лаеклы.

Шагыйрьнең бу җыентыгына «Өч тамчы су турында баллада», «Диңгез һәм солдатлар», «Яр буенда шаулый нарат» балладалары кертелгән. Бу әсәрләрендә солдат егетләрнең батырлыгын, туган илгә, хәрби антка турылыклы булуларын тасвирлый. Сугышта солдат гомере бик кыска була,— диләр. «Ышанмагыз, дөрес түгел, солдат үлми сугышта»,— ди шагыйрь.

Кинәт ут булып яна ул,
Я давыл булып үтә.
Халык телендә кала ул,
Җыр булып гомер итә.

Шактый уңышлы әдәби алымнар, истә кала торган образлар ярдәмендә һәм конкрет материал җирлегендә язылган бу әсәрләрне авторның тормыш вакыйгаларына, кешеләргә заманча мөнәсәбәте нинди икәнлегенә дә тукталып китик.

«Өч тамчы су» турындагы баллада, мәсәлән, «Сугышта бер тамчы су да солдатка гомер бирә» дип башлана. Кулына фляга тоткан командир яралы сугышчыларның берәвенә бер йотым су бирмәкче. Ләкин «Әчмәде ул бер тамчы да, тик фляганы үпте». Чөнки аның канлы ярасы, әйтерсең, дуслык сүзеннән үзе төзәлде, чөнки бер тамчы суга сусаган бүтән яралылар бар... Флягага, нәкъ шул солдат кебек үк, бүтән яралылар да авыз тидермиләр һәм ул «хуҗага» кире әйләнеп кайта. («Инде хәзер сезгә чират, әчегез, иптәш комбат»). Кайта... ләкин флягада өч кенә тамчы су булган икән...

Шушы өч тамчы суда, күргәнебезчә, дуслык, теләктәшлек, кыен чакта берберең ярдәмләшү, җаныңны ярып бирергә әзер булу хисләре Кояш булып чагыла? Нәби Дәүли балладаларында әнә шундый кырыс, романтик образлар ачыла.

Героик фактны поэзиядә шулай күрсәтү өчен шагыйрьнең зур гомумиләштерүләр, баһадир образлар белән эш итүгә аеруча уңай, аеруча ятышлы булган баллада жанрын сайлавы бик табигый. «Бу өлкәдә



ул шактый күп эзләнүчеләрнең берсе булды һәм шулай булып кала да. Ә эзләнүнең, ачышлар ясауның, яңаны табуның сәнгать үсешендә төп закон икәне билгеле.

Ләкин эш жанрның уңышлы сайлануында гына түгел бит әле. Әгәр материал бармактан гына суырып алынган булса, әсәрнең геройларына җанлы тормышның үз таләбеннән чыгып конкрет иҗтимагый бурыч йөкләтелмәсә, нинди генә «шома» техника белән язылган, баш әйләндергеч сюжетлы баллада да чын әдәби иҗат булып танылмас иде. Иҗади уңыш теләсә нинди очракта да шагыйрьнең дөньяны художник буларак күрер өчен аны тыштан күзәтүе белән генә түгел, ә материалга мөнәсәбәтнең ни дәрәҗәдә ачык һәм максатка ничек юнәлтелгән булуы белән хәл ителә»,— дип язган иде Зәки Нури «Тормыштан һәм тормышчан» дип аталган мәкаләсендә. («Казан утлары». — 1969.— №5.— Б. 143–151).

Шагыйрьнең «Берлинда окоп» дигән поэмасы — шулай ук балладага бик тартым әсәр. Ул фашизмга каршы аның үз оясында — Берлинда (шуңа күрә дә нинди көчле символика: «Берлиндагы окоп»!) торып көрәшкәндә һәлак булган Муса Җәлил һәм җәлилчеләргә поэтик һәйкәлләрнең берсе. Әйтергә кирәк, ул үзенең эшләнеше белән дә образлар төзелеше ягыннан да шактый үзенчәлекле һәйкәл! Анда Гитлер Германиясе, мәсәлән, менә ничек күз алдына китерелә: «Кошлар очмый хәтта ул якларга — курка алар тоткын булудан... Байрагында аның кара елан — дүрт тарафка карый дүрт башы... Безнең патриот егетләр шул илнең нәкъ үзәгендә көрәшәләр, ә дошманга төзеп атар өчен исә «сүздән коеп корал ясарга кирәк. Болар бар да, әлбәттә, баллада теле, баллада образлары!»

Әсәрне чын мәгънәсендә художестволы иткән сыйфат — аның гражданлык пафосы. Күрәсең, «гражданлык» төшенчәсен әсәрнең укучы йөрәгенә тәэсир итә торган көче буларак та, художестволылыкның бер шарты итеп тә, ниһаять, шагыйрьнең халык тормышы белән бәйләнеше нинди икәннен раслый торган факторларның берсе дип тә аңлау кирәктер.

Шагыйрьләрнең иҗатын нindидер бер төп сыйфат белән характерлый торган программ сүзләр була, мәсәлән, Тукайның бөтен иҗатын берьюлы күз алдына китерә торган «И туган тел, и матур тел»е бар. Ә М.Җәлилнең поэзиясен ачыклый торган «Мин җырымны илгә багышладым, гомеремне дә бирәм халкыма» дигән юллары. Нәби Дәүли иҗатының бәхетле үзенчәлеге дә аның тематик юнәлеше белән билгеләнә.

Ул юллар түбәндәге сүзләр:

Сугышларда орден алмадым дип,
Кайгырасым булмас үкенеп:
Киләчәктә туар фашистларны
Мин бүген дә йөрим үтереп.
Шуңа күрә туган ил каршында
Солдат итеп санайм үземне.
Киләчәктә туар көрәшчегә
Патрон итеп бирәм сүземне.

Шагыйрь шушы тезисыннан чыгып, лирик геройларын һәм укучыларын мәгънәле итеп, файдалы «эз калдырып» яшәргә өнди: «Дусишләрең, бәлки онытырлар, дошманнарың оныта алмасын...» Укучы бала мәктәптә «икеле» билгесе алгач та юкка еламасын, чөнки әле

алда тормыш дигән зур мәктәп бар — шунда «икеле» алучыларның хәле бик яман булачак. «Җирдә яшәү өчен, кулларында әгәр бетсә көчең, йөрәкне дә кирәк бирергә»,— дип йомгаклый Н.Дәүли.

Дуслык өчен йөрәгеңне куй табынга,
Мин ашамый тук булырмын шул чагында.
...Яшәдеңме җирдә дусны табып
Чын күңелдән сөя белдеңме?
Саф йөрәген аның үзеңә алып,
Йөрәгеңне аңа бирдеңме?

Тормыштагы теләсә нинди көчкә каршы тора алырлык, зур сынаулар кичәсе дуслык үзе дә зур, киң колачлы, җир шарының төрле почмакларында яшәгән бик күп кешеләрне берләштерә, бердәм итә торган дуслык булырга тиеш. Шагыйрь тынычлык өчен көрәшүчеләрнең бөтенесенең дә язмышын кайгыртып яши, шуларның барысы алдында үзенең шәхси җаваплылыгын тоеп иҗат итә, чөнки һаман болганыптузгып торган бу дөньяда битәнчә булу һич мөмкин түгел:

Без үлемнән җирне сакламасак,
Сез, чәчәкләр, нәрсә әйтерсез?!

Йөрәкләрне бер-берсенә якын иткән, көчкә көч өстәгән шул дуслыкны яклап һәм зурлап шагыйрь башкорт дусларына адресланган сүзен әйтә. («Шушы җирнең бер баласы итеп мин санарга телим үземне»), Корея кызын зур ышаныч белән юата («Уза алмас дошман синең йортка батыр дустың исән чагында»).

Манолис Глезосны яклап судта сөйлисе шигырен яза («Акропольнең биек гөмбәзендә дөнья күрер ирек байрагын!») Хулиан Гримау турында җырлый. («Туган халкыңа бирдең гомереңне, үзеңә бәхет эзләмәдең син... Үлем каршында тезләнмәдең син»). Вьетнам солдаты белән сөйләшә («һәр башактан берәр бөртек, һәр куактан берәр алма — Вьетнам солдатына»)...

Бер хулиган сындырып киткән һәм яфрагыннан яшь тамызып елаган шомырт агачы язмышы да, Испания трагедиясе дә бер үк дәрәҗәдә борчый аны. Ул Бухенвальд капкасына язылган сүзләргә дә үзеннән нәрсәдер өстәргә тели... Шуңа күрә шагыйрь, аңа военкоматта отставка кәгазе тоттырылгач та, бәхет өчен җирдә көрәш бара, шул фронтта минем окоп бар дип, һәм аннан аңа беркайчан да отставка булмаячагы турында горурланып яза.

Солдат шагыйрь турында сүз барганда, бу урында бер җырның «Солдат — һәрвакыт солдат» сүзләрен «Шагыйрь — һәрвакыт шагыйрь» дип үзгәртәсе килә. Ә Нәби Дәүли иҗатындагы палитра һәм интонацияләр муллыгын, бер ритмнан икенче ритмга бик оста күчүне күргәндә исә, ирексездән, поляк шагыйре Януш Корчак сүзләре искә төшә: «Шагыйрь ул бик көчле куана, бик нык кайгыра, бик тиз ачулана, бик каты ярата, хисләрне бик тирән кичерә торган кеше». Ә бу зирәк сүзләр күп төрле материалга бәйле бай фикерне һәм зур хисләрне чын мәгънәсендә художестволы итеп сурәтләү өчен тирән эчтәлекле образлар муллыгы, күләмле һәм картиналы сүз байлыгы кирәк дигән законга ишарә.

Нәби Дәүли шигърриятенең үзенчәлекле якларыннан берсе — әгәр кирәк икән, әгәр эчтәлек шуны таләп итсә, теге яки бу фактка яки предметка мөнәсәбәтле кыска фәлсәфи шигырьнең үзен тоташ бер образ итеп укучы күз алдына китереп бастыра алуы.

Менә аның «Солдат турында» нибары дүрт юллы поэмасы:



Атакага барган чакта
Солдат егылды.
Йөрәге аның суынды,
Ә җир җылынды.

Башкарган эшенең бөтен зурлыгы, язмышның бөтен фаҗигасе белән күрсәтелгән Поль Робсон:

Әйтерсең лә, моңлы җыры белән
Тирбәтә ул балам бишеген.
Үз йортында аның полиция
Көне-төне саклый ишеген.

Мондый һәм шуларга охшаш булган башка кыска әсәрләрендә («Игенче әлифе», «Минем паролем» һ.б.) күпме тормыш һавасы, күпме яшәү көче!

Н.Дәүли шигърриятенең тагын бер сокландыргыч ягы әдәбиятта күптәннән инде мәңгелек дип саналган теманы үзенчәлекле яңача чагылдыру өчен һич көтелмәгән яңа чаралар табуында.

Аның лирик герое яраткан кешесеннән «сөям» дигән сүз ишетер өчен әллә ниләр эшләргә әзер: болыннардан чәчәк җыеп келәм тукыр идем («хисләремне шуннан укыр идең»), ташка чокып сырлар идем уемны («әгәр шуңа кулың тисә, сизәр идең җылымны!»), кояр идем кылычтан («бусагаңны узмас иде бер дошман!»), сабакларын алтын кылга охшатып арыш үстерер идем («син кагылгач, шул алтын кыл әйтер иде минем теләкне!»). «Баскычлы» бу образның басмасыннан басмасына күтәрелгән саен саф мәхәббәт күрке ачыграк булып күренә, йөрәкләр тугрылыгына сокланууы арта бара.

Беренче бала туу шатлыгын шагыйрь түбәсе күкләргә тигән гиперболик образ ярдәмендә конкретлаштыра:

Туктармын һәрбер йортка,
Керермен парламентка.
Әйтермен: ил зурайды,
Җир тагын матурайды!
Нигә болай, дисеңме,
Парламентта сүз алам?
Әллә син күрмисеңме,
Җирдә бар минем балам!

*«Яшел ут — минем өчен!»*

Туган ягы табигать турында, тирә-як пейзажын сүз буяулары белән язганда без аны берьюлы шагыйрь дә, рәссам итеп тә күрәбез:

...Карлыгач төннәр буена
Йокламый ятты.
Оясына түбә итеп
Канатын япты.

* * *

Яфрак ярган инде иманнәр
Гаскәр кебек озын сафларда.
Яшел калган алар кигәннәр
Игеннәрнең гомерен сакларга...

Ташка җан өргән кешеләргә мәдхия, кеше акылына баш ию, азатлык өчен көрәштә корбан булганнарга дан җырлау кебек, җырга салуы авыр, ләкин җырланырга тиешле мөһим темалар Нәби Дәүли поэзиясендә предметсыз риторика, рифма сугыштыру өчен генә күтәрелмиләр. Шагыйрь үзенең әсәрләрен йөрәге белән кичереп,

шагыйрь булып яза. Әйтәсе сүзен ул йөрәгендә инде тәмам өлгереп җиткәч, хисләре ташый башлагач кына кәгазьгә төшерә:

Поездлар килә дә китә,
Дусларым кайтмый һаман,
Окоплар төшә исемә,
Авырта әле ярам.

Нәби Дәүли поэзиясенең тагын бер матур сыйфаты — аның күп кенә шигырьләренең гади хезмәт кешесе белән киңәш, җылы беседа формасында баруы. «Шигырь язу икмәк чәчүдән читенрәк» булса да шагыйрь үзенең авыр, җаваплы хезмәте белән масаймый. Киресенчә, кышкы зәмһәрир салкыннарда буран арасында йөргән колхозчы хатын турында уйлый, буровойда эшләгән дустын искә төшерә:

Ул әйтер кебек: — Синең өеңдә
Җылы да булсын, якты да булсын.
— Җылы да миңа, якты да миңа,
Сиңа вышкада салкындыр, дустым.

*«Тышта кар ява»*

Яңа йорттан фатир алган иптәшенә үгет — нәсыйхәт бирә, улын сагынган карчык — ананы юата:

Җыр юлы авыр, җыр юлы ерак,
Давыл булса да, һаман барасы.
Улың кайтмаса — саргайма елап,
Шагыйрь анасы — солдат анасы.

*«Шагыйрь атасына»*

Мондый шигырьләр рәтенә «Матурлык турында», «Оныкларым белән сөйләшү», «Архимедка хат», һәм башка бик күп шигырьләрне кертергә була. «1945 нче ел шигыре» исә лирик бизәкләрнең төрлелеге, элегик чигенешләрнең байлыгы белән әлеге шигырьләрдән аерылып тора. Шигырь сугыш бетү вакыйгасы белән башланып китә.

Солдат яткан окопларда
Ямь-яшел үлән үсте.

Бу гади сүзләр генә түгел. Бу — җиңү, тынычлык аккорды. Сугыш бетте, ләкин аның канлы эзләре, җуелмас тирән җәрәхәтләре калды.

Аллы-гөлле тасмаларны
Җилфердәтеп җил исә.

Шигырьдә әле һаман бөек тантана тасвирланса да, шатлык вәгъдә иткән строфаның өченче юлында үк кискен борылыш ясала:

Ә син нигә шатланмыйсың,
Ник моңайдың, Нәфисә?

Бу — кайгы белән шатлык арасындагы чик. Нәфисәнең сөйгәне яу кырында мәңгелеккә ятып калган. «Нәфисәнең кайгылары китәрлек түгел».

Күз яшьләре тамчы гына,
Ташка тамса — таш сизәр.
Таш сизәрлек кайгыларга
Нәфисә ничек түзәр?

Әгәр дә шигырь шушы урында тәмамланса, күңелдә пессимизм хисе калыр иде. Әмма, Нәби Дәүли үзенең «тормышымда кайгы юлдаш түгел» дигән сүзләрен тулысынча раслый. Нәфисәнең китек күңеленә сак кына, йомшак кына кагыла ул. Тол кәләшкә ата булып та, иптәш булып та, шагыйрь булып та эндәшә:



Сиңа гына килгән кайгы түгел,
Йә, елама инде, Нәфисә.

Әнә шулай әкренләп Нәфисәнең кайгысы ил кайгысына барып тоташа.

«Син генә түгел, ил белән бит» дигән фикер елаучыга юатучы тарафыннан ышандырырлык итеп төшендерелә. Шигырь моның белән генә чикләнми әле. Нәфисәнең күз алдына сугыш картиналары бөтен дәһшәте белән килеп баса. Юатучы һаман сөйли:

Җир дә язын чәчәк атмас иде
Ул солдатның каны таммаса...

Һәм, ниһаять, югары башлаган хәсрәт болытларын аралап, оптимизм кояшы нур сиба:

Күтәрергә безгә шәһәрләрне
Ташлар гына калган өемнән.
Елаудамы безнең яшәү яме,
Нигә безгә йөрәк бирелгән?

Нәби Дәүли яшәү белән үлем арасын узган шагыйрь. Шуңа күрә дә аның тормыш, туган ил, икмәк турындагы шигырьләре аеруча тәэсирле, көчле, пафослы яңгырыйлар. Шагыйрь җирдәге һәртөрле җәберләүләрне, гаделсезлекләрне күрә алмаган кебек, «кеше гомерен талап» яшәүче тираннарны, мәкерле сугыш чукмарларын, комсыз Гансларны, гайбәтче Гарриларны да рәхимсез фаш итә.

Нәби Дәүли киң диапазонлы шагыйрь. Аның сәяси, сатирик шигырьләре дә, балладалары да бер үк дәрәҗәдә уңышлы. Сатирада усал, юморда гаҗәп күңелле, лирикада искиткеч моңлы, ләкин шуның белән бергә бөтен йөрәге белән оптимист шагыйрь ул.

Кем булсам да, яшәү матурлыгын
Табар идем хәтта сахрада.
Пессимизм дигән микробларны
Йөрәгемә салып асрамам,

дип әйтүе дә буш сүзләр генә түгел.

«Авыл дәфтәре» Нәби Дәүлинең иң уңышлы әсәрләреннән берсе. Җанры буенча егермеләп новелланы берләштергән бу шигъри романда, Фаил Шәфигуллин әйткәнчә: «Һәр битендә тыгыз динамика, гармоник камиллек бар.» Әсәр Нәби Дәүли поэзиясенә генә хас шигъри аһәң, авыл кешеләренә тирән мәхәббәт белән сугарылган. Аңарда табигать күренешләре белән философик төсмерләр, лирик детальләр белән юмор элементлары бербөтен булып үрелгәннәр.

Дәфтәрнең беренче битендә үк назлы, юмарт авыл табигате үз кочагында тибрәтә башлый. Бернинди киртә, бернинди бусага юк. Әсәр үзеннән-үзе укыла, аны укыган саен укыйсы килә, укыган саен күңелдә нииндидер ямь, куаныч арта. Ә дөньяның ачысын-төчесен татыган кеше өчен бу җирләрдән узу икеләтә рәхәт. Андый кешенең:

Әгәр инде арса аякларым,
Шунда туктап мин ял итәрмен.
Мин окопта ятып тойган кеше
Җир түшәктән йомшак икәнен,—

дигән сүзләренә ышанмый мөмкин түгел.

Дәфтәрнең икенче бите борын-борын заманнан килгән зур дуслыкка — руслар һәм татарлар дуслыгына багышланган. Шагыйрь:

Яз ташкыны бозлар агылган
Бергә саклый алар күперне,

дип бу дуслыкны символлар һәм реаль күренешләр аша яктырта.

Кешенең тормыштагы роле, җәмгыятьтә тоткан урыны хакында фәлсәфи уйланулардан, гыйбрәтле диалоглардан торган өченче бит өчен гражданлык мотивлары хас.

Доктормы син, әллә эшчеме син,
Дөнья кудың әллә бушкамы?—

дип сорый колхозчы хатын шагыйрьдән. Бу сорау шагыйрьне үз вөҗданы белән ачыктан-ачык сөйләшүгә китерә, аның күңелендә бүгенге поэзиянең бурычлары турында тагын да тирәнрәк, тагын да җитдирәк сораулар туугa сәбәпче була. Шагыйрь, бер яктан, авылдашы белән гади әңгәмә алып барса, икенче яктан, сәнгать осталарының идея мораль сыйфатлары турында уйлана, әлеге җитди сорауларга җавап эзли. Һәм, ниһаять, дәфтәрнең уналтынчы битендә өлешчә булса да бу сорауларның кайберләренә җавап табыла:

Начарларны яхшы кеше итү —
Поэзиянең бөек бурычы.

Героемны әгәр начар дисәм,
Моның өчен кемнәр гаепле?

Шагыйрь каләм остасы, педагог буларак, иң зур гаепне үз иңенә ала. Үз героеның мораль яктан гарип булуы өчен ут йота, аны дөрес юлга чыгару, тәрбияләү чараларын табарга тырыша.

Берсеннән-берсе матур эпизодлар алышынып, битләр берсе артыннан икенчесе ачылып тора. Кабатланмас образлар, характерлар синең күңелеңә гомер буе онытылмаслык булып урнаша бара. Түбәсендә күгәрченнәр гөрләгән тату гаилә дә, бал яратучы малай да, эшчән кызлар да, тынгысыз Хәсән бабай да, Мифтах та, Әпсәләсе дә озакламый синең иң якын танышларыңа әвереләләр. «Укучы, авторның үзен онытып, автор күрсәткән кешеләрне генә күрсә һәм ишетсә, сәнгать менә шуннан башлана»,— дип юкка гына әйтмәгәндер М.Горький.

Китапта актуаль темага язылган әсәрләрнең берсе «Кеше турында монолог.» Шагыйрь бу әсәрендә дә кеше турында, аның язмышы турында борчыла. Бу шигырь үзенең мәгънәви тирәнлеге, тәэсир көченең зурлыгы, публицистик детальләргә киң урын бирелүе, фәлсәфилеге, масштаблыгы белән үзенчәлекле.

Ә менә «Кесә дәфтәре» дигән бүлеккә тупланган шигырьләр үзләренең эмоциональ киеренкелеге, төрле ассоциацияләргә бай булуы белән күңелне җәлеп итә. Күп кенә шигырьләр турыдан-туры халык авыз иҗатына барып тоташа, канатлы сүз, афоризмнар булып хәтергә сеңеп кала. Мәсәлән:

...Атом табу җиңелрәк
Чынын сөйли белүдән...

...Җирдән ашарга теләсәң,
Үзең дә җирне ашат...

...Күзләре күрмәс булды,
Аягы йөрмәс булды,
Дөньяны белмәс булды,
Йөрәге үлмәс булды...

Муса Җәлилнең үлемсез образын гәүдәләндергән әсәрләр күп бездә. Алар арасында романтик биеклектән торып, символик сурәтләү чараларына таянып иҗат ителгәннәре дә, патетик рух белән сугарылган реализм күренешләреннән үрелеп язылганнары да бар. Нәби Дәүлинең «Берлинда окоп» дигән поэмасы соңгылар рәтендә. Башка әсәрләрдән нәрсәсе белән аерылып тора соң бу поэма? Беренчедән, әсәрнең буеннан-буена сузылган тирән моңы белән. «Ә мин моң төшенчәсен билгеле бер халыкның узган юлы, тарихы, туган җиреннән эзлим»,— ди Сибгат Хәким. Икенчедән (шагыйрь әсирлекнең коточкыч газапларын үзе кичергәнгәдер, мөгаен), поэмадагы барлык ситуацияләр дә урынлы, табигый. Әсәрне Мусаның күзгә күренмәс җан дусты, аның вөҗдан тавышы булып, һәрвакыт аңа эндәшү, аның белән сөйләшү формасында язу бу табигыйлекне тагын да көчәйтә төшкән. Өченчедән, лирик чигенешләрнең, чит ил сүзләренең, юмор элементларының мул булуы поэмадагы мөһим эпизодларның вaклануына, вакыйгаларның торгынлыгына китермәгән. Поэма гомумхалык биеклегендә, поэма хәрәкәттә.

Поэманың йөрәге герой йөрәге белән бер ритмда тибә. Гомумән, Нәби Дәүли шигърияте ике төп сыйфатка зур гомумиләштерүләргә һәм ачык гражданлык пафосына омтылуы белән аерылып тора. Шагыйрьнең сайланма әсәрләренә язган кереш мәкаләсендә шагыйрь Зәки Нури да әнә шуңа игътибар итә һәм: «Көрәсең, «гражданлык» төшенчәсен әсәрнең укучы йөрәгенә тәэсир итә торган көче буларак та, художестволылыкның бер шарты итеп тә, ниһаять, шагыйрьнең халык тормышы белән бәйләнеше шунда икәнен раслый торган факторларның берсе дип тә аңлау дөрестер»,— дигән нәтиҗә ясый. Нәби Дәүли иҗатының заманча һәм халыкчан яңгырашы кайдан килә дигән сорауга моннан да төгәлрәк итеп җавап бирергә мөмкин түгел. Нинди генә газаплар кичерсә дә, шагыйрьнең күңеле суынмаган, хисләре тупасланмаган. Ул үзенең төп принципларына, тематик юнәлешенә һәрвакыт тугрылыклы кала. Аның әсәрләрендә иркәләп — шаяртып, ә кайчак шактый усал һәм ачы итеп көлү дә, нечкә психологизм һәм кыю публицистика да, «поэзиядә географик чикләр юк, анда идея чикләре генә бар,» дип, ил-көн, җир язмышы өчен борчылу да урынлы яңгырый.

Шагыйрь язмышындагы сугышка кадәр һәм сугыштан соңгы чорларны берсеннән-берсе биегәя төшкән үрләр белән тиңләргә мөмкин. Үрдән-үргә менгән саен шагыйрьнең күз күреше ерагая, дөньяга карашы киңәя, иҗат уңышлары ишәя бара. Кыскасы, Нәби Дәүли шигърияткә үзенең зур биографиясе белән тормыштан килгән, аны тормышчан темалар һәм интонацияләр белән үзенчә баеткан шагыйрь.

**СИРИНӘ МИННЕГАЛИМ,**
ТР Мәгарифне үстерү институты
доценты.



5 Т-1408